ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2025 с.Старое Дрожжаное №559

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы (06.05.2019 N 380, 16.04.2020 N 294, 01.09.2020 N 768, 03.11.2020 N 989, 21.07.2021 N 633, 26.07.2021 N 645, 30.10.2021 N 1030, 26.05.2022 N 489, 20.06.2022 N 587, 14.09.2022 N 1002, 30.11.2022 N 1268, 17.07.2023 № 846, 03.04.2024 № 215, 26.04.2024 № 283, 21.06.2024 № 447, 12.09.2024 № 766, 18.04.2025 № 245, 17.09.2025 № 708 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарының гамәлен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларына таратырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән җитди хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 05 маендагы 145 номерлы «Татарстан Республикасы

Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларына үзгәрешләр кертү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов